## *«Хәтер» китабына*

# СЕБЕРГӘ СӨРЕЛГӘН СОЛДАТ

Сәгыйть ага Гобәйдуллин белән очрашкан саен Кәбир бабай Якуповны искә алабыз. Ул—шикәрчеләр поселогында, аның белән янәшә урамда яшәгән күршесе, минем авылдашым. Икебез дә Чүпрәле районының Татар Төкесеннән чыккан кешеләр.

—Кызу холыклы иде, мәрхүм,—ди Сәгыйть ага. —Берәр нәрсәгә ачуы килсә, «Колак артыңа менеп төшәрмен дә, каталап («тәгәрәп» сүзенең безнең якта кулланыла торган мишәр диалекты. Автор аңлатмасы) китәрсең»,—ди торган иде.

Гомеренең соңгы елларында аралашып яшәргә туры килгәнгә беләм, Сәгыйть ага әйткәннәр хак, җитмеш яшен узгач та, тиз кабынучан һәм тиз сүрелүчән, гадел сүзле кеше булып калды ул. Һәм, әйтергә кирәк, шул туры теле аркасында заманында күпме кыен күргән, Себергә кадәр сөрелгән кеше ул.

...Яшьлеге һәм үсмер чагы авырлык белән үтә аның. Гражданнар сугышыннан соң ук ялланып такта ярып йөргән. Аның ул еллардагы кулдашы минем әти Заһретдин булган. Шул чордагы бер очрак турында әти мәрхүм сөйләгәне бар. Такта яручылар булып эшкә яллангән беренче кичтә, азыкка тарыгач, чаманы белми ашап ташлыйлар. Аңа кадәр ачлыкка интеккәнгә, тамакларын тыя алмыйлар. Шуннан төне буе эчләре борып, иза чигеп чыгалар. Хуҗа аларга чирләренең сәбәбен аңлата. Шуннан соң, тамак мәсьәләсендә саграк кылана, чамасын белеп туена башлыйлар.

Авылдашымның аннан соңгы тормыш сукмагына да гөлләр сибеп куймаганнар: тормыш итү, гаиләсен асрау өчен күп көч куярга туры килә. Хәер, дөнья җимерттерә торган гайрәтле, куәтле чагы колхозда куйган хезмәтеннән тыш та кулларына эш таба. Татар Төкесенең уңай ягы, авыл Чувашия урманына сыенып диярлек урнашкан. Халыкның арка терәге ул урман: җәен җиләк-җимешен җыя, мал асрау өчен печәнен чаба, кышка керсә урман кисү, чыбык-чабыгын яндыру белән шөгыльләнә. Югыйсә, биредәге колхоз мөстәкыйль чагында да аз һәм уңдырышсыз җирле, авылны икмәк түгел салам белән дә тәэмин итә алмый. Шуңа карамастан, авыл халкы, хезмәтен икеләтә кую бәрабәренә, урмансыз зона халкыннан чагыштырмача тәэмин ителгән хәлдә көн кичерә. Дала зонасындагы авыллардан райондашлар йортын сатып яисә тәрәзәсен кадаклап сугышка кадәр Донбасс шахталарына, соңрак Ульяновск якларына агылган бер моментта Татар Төкесендә яңа урманнар үсеп чыга әле. Әмма алтмышынчы елларда перспективасызлар рәтенә кергәч, яшьләр аннан да, шыгырдап, сагыз исе аңкып торган йортларын бикләп, кадаклап китә башлыйлар. Хәзер инде буш нигез адым саен авылда.

Укучы бу юлларны темадан читкә китү дип кабул итүе ихтимал. Ләкин туган авылым хәлен белә торып чигенеш ясадым, алар бу язманың герое Якупов язмышына да турыдан-туры кагылышлы.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Кәбир Якупов та хәрби хезмәткә алына. Хатыны Сәрбиҗамал берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән кала.

Солдат гомерен пуля, снаряд астына куеп Ватан иминлеген яклап сугыша. Мең үлемне үтеп исән кала.

Ул кан коеп йөргән арада гаиләсе корбаннарга дучар була. Авылда ул чордагы тормышның күз алдына китерү дә коточкыч: 1944 елны күпме халык ачтан кырыла. Сәрбиҗамал апа мәрхүмә икмәккә йортны алмаштырып мунча кадәрле генә өйгә күчә. Бәрәңгенең поты йөзәр, онның меңәр сум исәпләгәндә, йортның бәясе нибары берничә пот ашлыкка тиң булганда ачлыктан киселгән гаиләгә моның ярдәме күпкә җитми: балаларының икесе үлә.

Гаиләне кырылып бетүдән, әлеге дә баягы, урман коткарып кала. Язга чыгу белән авыл халкы урманга ябырыла: кычыткан, кузгалак һәм башка ашарга яраклы үлән эзләп көн саен ераккарак керергә туры килә. Аннан анда җиләк-җимеш өлгерә башлый. Яңа уңышка шулай килеп ялганалар. Сәрбиҗамал апа шулай бер очтан урманга «ухалла» арбасы тартып йөри: кышлык өчен ягулыкка ботак, чыбык төяп кайта.

Кәбир солдатны гаилә түбәсенә түшәм генә җәелгән мал абзарын хәтерләткән шул өйчектә каршылый. Кулыннан төрле эш килгән ир-ат өчен хезмәт җитәрлек була, билгеле. Колхоздагы—анысы, дөресен әйткәндә, «таяк»ка, ягъни бушлай эшләү—хезмәте өстенә йорт-җирне көн итәрлек итү өчен көч куя. Сыер җигеп урманга йөри, утыны өй өчен генә түгел, сатарлык та арта башлый. Ә бу гаиләнең бердәнбер акча кереме: налог, заем һәм шул чордагы башка салымнар өчен түләүләргә чыганак: гаиләгә чәй-шикәр, кием-салымга да шуннан өлеш чыгарырга туры килә.

Ир-ир инде, кыеплык белән булса да гаилә көчкә-көчкә тормышның очын очка ялгап бара ала. Әмма бәла аяк астыннан килеп чыга. Кәбирнең шул, халык әйтмешли, «чагалы» теле, ягъни туры бер сүзе аркасында.

..Колхозда гомуми җыелыш бара. Язгы чәчүгә хәзерлек турында сүз чыккач ат караучы Якупов, тынгысыз җан, «атлар Хәдичә туны киде инде» дип каршы сүз әйтеп ташлый. Мәгънәсе: атлар ябык, чәчүдә катнаша алулары икеле. Ул чакта атлар колхозның кыр эшләрендә төп көче була, фронтовик шуңа борчыла, аларга игътибарны —бу очракта азыкны беренче чиратта, әлбәттә—арттыру кирәклегенә ишарәли. Әмма шул чактагы колхоз рәисе Хәлим Туктаголовның мин-минлегенә тия хакыйкать. Фронтовик ат караучы сүзләреннән гомуми файдага нәтиҗә ясыйсы урынга, аның үзенә ябыша. Җыелышта партия, хөкүмәт политикасына каршы чыгыш ясады дип бәяли. Аны яклаучы куштаннар да табыла. Якуповны колхоздан ук чыгарып ташлыйлар, МГБның (дәүләт иминлеге министрлыгы) район бүлегенә хәбәр итәләр.

Ул елларда репрессияләр шаукымы йомшый төшкән була инде. 1937 ел булса мондый сүзләре өчен турыдан-туры ГУЛАГның бер лагерына эләгәсе Якуповка җәзаның җиңелрәге эләгә.

Хәер, колхоздан куылганнан соң бер ел чамасы вакыт авылда яши әле гаилә. Туктаголов үчен итә бирә, язга чыккач бәрәңге бакчасына колхоз өчен тары китереп сиптерә. Гаилә көн итү өчен соңгы чыганактан да мәхрүм кала. Башка колхозчыларның да коты алынып торсын, гыйбрәт булсын өчен эшли моны Туктаголов. Якупов аңа ялынсын, алдына тезләнсен өчен. Шулай була калса, район органнары алдында аның файдасына сүз әйткән булыр иде. Ләкин баш ияме соң Кәбир?! Андый булып тумаган шул.

Үзенең хаклыгын белсә дә, ике ут арасында кала давыллар кичкән солдат. Читкә китсә, һәркөн янап торган куркынычтан котылып каласын да белә, ләкин... Бер карасаң, ул ирекле, колхоз члены түгел. Икенче яктан, кулында паспорты юк һәм Туктаголов аны алырга белешмә бирми: ул беркая китә алмый. Аның ул чордагы хәле турында уйлаганда тозакка эләккән бүрене күз алдына китерәм. Ул, ерткыч булса да хайван, кызыл флаглар утыртып чыгылган зонага килеп эләгә дә, шуннан ычкына алмый: флагны күргән саен артка чигенә. Кәбир солдатның хәле дә нәкъ шулай: куркыныч янаганын белсә дә, берни эшли алмый, тозактан ычкыну юлы юк. Ул чактагы система шулай корылган: чынбарлык турында бер хак сүз әйтүче табылса, үзеннән-үзе «капкынга» килеп эләккән.

Якупов, аптырагач, Чувашиянең Шымыршы районы Күчәк авылына китеп урнаша. Ул вакытта Шымыршы урман хуҗалыгына яндырып агач күмере хәзерләү заданиесе җиткерелә. Ул күмерне, хәтерлим, колхозларга һәм халыкка сатып та йөриләр иде әле.

Күчәк урман эчендәге, аулак поселок, эшкә урнашу өчен паспорт һәм прописка да кирәкми. Әмма МГБның күз угында торган Якуповны бу да коткара алмый. Кышкы төннәрнең берсендә, ниһаять, милиция хезмәткәрләре бирегә дә килеп җитәләр. Хатынын, балаларын елатып аны алып китәләр. Олы улы Вахит «Әтине калдырыгыз» дип тәкрарлый-тәкрарлый чана артыннан йөгерә. Миһербансыз милиционерлар аның тавышын ишетмәс өчен атны камчы белән куалар. 12 яше дә тулып җитмәгән малай чана эзеннән, кара урман эченнән Татар Төкесенә кадәр 7 чакрымны ялгыз чыга, туганнарына хәбәр итә. Тик моннан ни файда?!

Шуннан соңгы вакыйгаларның бер кадәрен үзем дә хәтерлим. Кәбир ага кулда чакта хатыны Сәрбиҗамал апа (минем өчен адаш апа, чөнки әниемнең дә исеме шулай иде) Себергә озатырга алып килгәч, имүдән аерылмаган төпчек улы Хатыйп белән безгә килде. Сугыштан соң туган Нәкиясе абый, апасы белән калган булса кирәк. Без ул чакта Чүпрәледә яши идек. Ул ачыктан-ачык килгәнме тәгаен әйтә алмыйм, чөнки әтинең милициядә эшләгән чагы, андый гаиләләр белән аралашуны хезмәтендә хуп күрмәгәннәрдер дип уйлыйм. Ничек кенә булмасын, ике ананың кайгыдан елашулары, сөйләшүләре, яшь баланы чорнарга чүпрәк җыюлары хәтеремдә. Кызгану хисе белән ул кичерешләр минем—тугызынчы яшьтәге малайның хәтерендә яхшы сакланган. Әти мәрхүм эштән кайткач, аның белән дә киңәш-табыш кордылар. Ул адаш апага авылда калырга, иренең фронтовик, дүрт баласы булуын исәпкә алып, элекке кулдашын озак тотмый җибәрерләр дигән фикер белдерде. Моны ул ихлас күңелдән сөйләвенә ышанам: Себергә сөрелгән кулак һәм башкалар гаиләләренең юлда барганда ук күпләп кырылуы турында хәбәрдар булган ич ул, шуңа гаиләне саклап калу теләгеннән киңәш иткәндер дип уйлыйм. Адаш апаның җавабын соңыннан, күп еллар үткәч, үз теленнән ишетеп белдем: үлсәк тә бергә үләбез. Һәм ул хак булып чыга: аның ире ише гаепләнүчеләрне ялгыз булган очракта турыдан-туры ГУЛАГ лагерьларына озата баралар. Аннан кайта алган булыр идеме Якупов—әйтүе кыен.

Аларның язмышы икенче сукмактан китә. Хөкем карары чыгарганда гаиләсенең дә төрмә йортында ирекле тоткын (башкача билгеләмә юк) булып яшәгәнен исәпкә алып, политик тоткын саналса да, Калыма урынына Себергә озату белән алмаштыралар, «игелек эшлиләр». (Закон чекистларның үз кулында — ничек тели, шулай хөкем итә). Дүрт яшь баласын иске-москыга чорнап кышкы чатнама суыкта 60 чакрым ераклыктагы Борындык тимер юл станциясенә конвой астында озаталар. Без мәдхия җырлаган декабрист хатыннарының пар атларда, толыпка төренеп ирләре артыннан Себергә баруы Сәрбиҗамал апа өчен күңелле бер сәяхәт кенә булыр иде.

Казан төрмәсендә алар ише тоткыннар шактый җыелгач, Амур өлкәсендәге совхозларның берсенә озаталар. Политик хокуклардан мәхрүм һәм совхоздан читкә чыга алмый бу гаиләләр.

Ат белән су ташучы булып эшли Якупов. Балаларның өзелгән укуы, ниһаять, юлга салына, мәктәпкә йөри башлыйлар, тормыш үз эзенә төшә кебек. Әмма дымлы, салкын һава, еш алмашынучан климат интектерә, даими чирлиләр. Күргән михнәт, кыерсытып карауга җан әрнү газаплары үзе бер китап. Һәм шунысы да бар: 7 тапкыр сөргендә булган Сталин аның чиреген дә татымаган.

Н. С. Хрущев чорында башланган җылылыкның аларга да файдасы тия: Кәбир солдатның да хокуклары кайтарыла, ирекле яшәү рөхсәт ителә. 1958 елның җәендә төянеп яңадан туган туфракка кайтып егылалар.

Туган якта да сөенечләр көтеп тормый гаиләне. Колхоз бригада гына булып калган, эш юк. Балаларның олылары—Вахиты һәм Наҗиясе үз көнен үзе күрергә чыгып китә. Вахиты Норлатта төзелә торган шикәр заводына эшкә килеп урнаша. 60 нчы еллар башында, 40 сум каравыл акчасына көн күреп булмасын аңлаган Кәбир карт янә кузгала, шикәр заводы поселогында улы алган нигезгә күченеп килә, йорт өлгертеп керә.

Ике күчү бер януга тиң диләр халыкта. Янгын бернине калдырмый. Гаиләгә яңа урында тормышны яңабаштан башларга туры килә. Бу күченүнең ул исәпләмәгән тагын бер кыен ягы ачыла: колхозда эшләгән еллары анда пенсиягә чыкмагач, берни кирәксезгә кала. Җиң сызганып стаж җыярга туры килә. 65 яше тулганчы хезмәт куеп та нибары 19 ел производство стажы туплана. Анысы да Себер сөргенендә совхоздагы хезмәтен кушып кына.

1974 елның җәендә үзечә әйтсәк, Заһретдин (минем әти) малаеның, ягъни бу юллар авторының Норлатта яшәвен ишетеп, хезмәт урынымнан үзе эзләп тапты. Аңа кадәр без якыннан таныш түгел, берберебез хакында ишетеп кенә белә идек. Чит-ят җирдә авылдашны очрату туганнан да артык бит ул: аралашып киттек, сирәк булса да очраша, кунакка йөрешә башладык. Ул чагында Кәбир карт 70 яшен тутырса да һаман кызу, темпераментлы, энергияле иде әле. 35 сум гына (тулы булмаган стаж өчен) пенсия алганга, ялга чыккач та җәйләрен балтасын тотып эшләп алгалый иде әле.

Бүген, эш узгач, политик тоткын чаклары турында сорашмавым өчен күңелдән үземне тиргим. Язмышның иң кыен, гаделсезгә эзәрлекләнгән этапларын искә төшерү уңайсыз санадым. Бусы бер, ләкин төп сәбәп түгел иде. Гомеренең соңгы елларында сталинизм яңадан тамыр җәя, көчәя барган чор, аның ишеләр турында телгә алу да хәтәр эш, бүгенге үзгәртеп корулар безнең күз алдына да килми иде әле. Кәбир карт аклану кәгазе, сугышчан медальләрен кайтару турында да сүз кузгатырга шикләнә, горурлыгын басып килә. Вөҗдан саф булгач, шул җитә аңа. Хак сүз өчен янә «янарга» мөмкин икәнен чамалый, башыннан үткәннәр турында да берәүгә дә тел ачмый. Ул чор турыда язарга без журналистлар да хаксыз идек. Хәзер аның турында истәлекләрне берәмтекләп тупларга туры килде.

Кәбир Якупов язмышы —Сталин бер гаепсез юк иттергән миллион корбаннар күргән михнәтләр янәшәсенә куеп караганда азагы хәерле беткән тарих. Әмма ул Сталин законнары алдында да баш имәгән, намусына хилафлык кылмаган кеше. Шуның өчен күңелләрдә сакланырга лаек шәхес.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

